ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-30-61; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **КҮРСӘТМӘ**

«28» август 2020 ел № 85-р

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе кысаларында җыелган акчаларны бүлү комиссиясен раслау турында**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе турында» 2020 елның 21 июлендәге 7788/20 номерлы хаты нигезендә:

2020 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе кысаларында җыелган акчаларны бүлү комиссиясен түбәндәге составта расларга:

- Гыйльметдинова Римма Ринат кызы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары, комиссия рәисе;

- Сафиуллина Вәсилә Гарәфетдин кызы - «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары;

- Зиновьева Ландыш Илфар кызы - "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы мәгариф идарәсе" муниципаль казна учреждениесенең баш белгеч-юристы, комиссия әгъзасы;

- Зиннәтова Назилә Мехаматнур кызы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы район советы депутаты, комиссия әгъзасы;

- Яппарова Лилия Дуфар кызы - Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Әгерҗе шәһәренең «Бәләкәч» 7 нче балалар бакчасы муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе мөдире, комиссия әгъзасы.

2. Мәгариф комиссиясенә «Мәктәпкә җыенырга ярдәм ит» республика хәйрия акциясе кысаларында җыелган акчаларны бүлү эшен 2020 елның 31 августына кадәр төгәлләргә, «мәктәп портфелен» тантаналы тапшыру буенча чаралар үткәрергә.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2020 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге күрсәтмәне Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында

Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары Р.Р. Гыйльметдиновага йөкләргә.

**Җитәкче вазыйфаларын башкаручы** **И.И. Шәмсетдинов**